РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 42

2022 елның 26 августы

# Түбән Кама муниципаль районы Советының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 48 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларга Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм хезмәткәрләрнең вәкаләтле вәкилләре арасында төзелә торган социаль партнерлыкның территориаль-тармак килешүендә каралган күләмнәрдә һәм нигезләр буенча түләүләр башкарылырга мөмкин.

Күрсәтелгән килешүдә каралган бер тапкыр бирелә торган түләү даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләп торучы затның яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның эшкә кабул ителгәннән соң унбер айдан да иртәрәк булмаган шәхси гаризасы нигезендә башкарыла.»;

2. Түбән Кама муниципаль районы Советының «Түбән Кама муниципаль районы бюджет өлкәсенең Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 49 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Җитәкчеләргә, белгечләргә, хезмәткәрләргә һәм эшчеләргә Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм хезмәткәрләрнең вәкаләтле вәкилләре арасында төзелә торган социаль партнерлыкның территориаль-тармак килешүендә каралган күләмнәрдә һәм нигезләр буенча түләүләр башкарылырга мөмкин.

Күрсәтелгән килешүдә каралган бер тапкыр бирелә торган түләү җитәкче, белгеч, хезмәткәр яки эшченең эшкә кабул ителгәннән соң унбер айдан да иртәрәк булмаган шәхси гаризасы нигезендә башкарыла.»;

3. Түбән Кама муниципаль районы Советының «Түбән Кама муниципаль районында аерым муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны премияләү буенча Түбән Кама муниципаль районы башлыгы каршындагы комиссия турында» 2014 елның 18 декабрендәге 45 номерлы карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

Түбән Кама муниципаль районында аерым муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны премияләү буенча Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы каршындагы комиссия турында нигезләмәнең 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- аерым муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга бер тапкыр бирелә торган түләүләр, матди ярдәм һәм мондый түләүләр күләме турында карарлар кабул итү.».

4. Әлеге карарның 3 пункты үз гамәлен 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә тарата.

5. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-икътисади үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы,
Башлык урынбасары

А.В.Умников